Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Кәләй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 12 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй авылының Дуслык, Елга, Заречная урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Кәләй авылында мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Специалистлар урамы, 2В йорты.

2. 2019 елның 12 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй авылының Специалистлар урамында, Токарликов урамындагы № 1-35 йортларында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Специалистлар урамы, 2В йорты.

3. 2019 елның 13 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй авылының Токарликов урамындагы № 36-133 йортларда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Кәләй авылында мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Специалистлар урамы, 2В йорты.

4. 2019 елның 13 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй авылының Токарликов урамындагы № 134-231 йортларда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Специалистлар урамы, 2В йорты.

5. 2019 елның 14 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй авылының Тукай, Рангаут, Урта, Урман урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Кәләй авылында мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Специалистлар урамы, 2В йорты.

6. 2019 елның 14 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй авылының З.Г.Шәйдуллин, Мәктәп урамнарында үзара салым акчаларын

кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Специалистлар урамы, 2В йорты.

7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кәләй авыл җирлегенең Кәләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Кәләй авылы территориясендә парк зонасын төзекләндерүгә, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрүгә түләү өчен тоту?”

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Кәләй авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

9. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл башкарма комитетын билгеләргә.

10. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кәләй авылы, Специалистлар урамы, 2Д йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кәләй
авыл җирлеге башлыгы В.Б. Воронин